Татарстан Республикасы

# ЗАКОНЫ

**Аерым муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен үзгәртү һәм "Азнакай муниципаль районы" муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында" Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2010 елның 22 апрелендә
кабул ителде

**1 статья**

Азнакай муниципаль районы составына керүче "Актүбә шәһәр тибындагы поселогы", "Мәлбагыш авыл җирлеге" һәм "Микулино авыл җирлеге" муниципаль берәмлекләренең территорияләре чикләрен әлеге Законга кушымта нигезендә үзгәртергә.

**2 статья**

"Азнакай муниципаль районы" муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында" 2005 елның 31 гыйнварындагы 48-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2005, № 1 (IV өлеш); 2008, № 8 (III өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Азнакай муниципаль районы" муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында" Татарстан Республикасы Законына
1 нче кушымта

# "Азнакай муниципаль районы" муниципаль берәмлеге составына керүче муниципаль берәмлекләрнең чикләре

## карта-схемасы




Шартлы билгеләр

- республика чиге
- муниципаль район чиге
- тоташу ноктасының тәртип саны
- жирлекләрнең чикләре һәм аларның сан белән билгеләнеше
- торак пунктлар
- муниципаль районның административ үзәге
- жирлек үзәге

Муниципаль районның чиктәш чикләре тасвирламасы

| | |
|---|---|
| 12 (21) - 54 (22) | - Башкортостан Республикасы |
| 54 (22) - 34 (74) | - Ютазы муниципаль районы |
| 34 (74) - 26 (73) | - Бөгелмә муниципаль районы |
| 26 (73) - 7а (72) | - Әлмәт муниципаль районы |
| 7а (72) - 2 (71) | - Сарман муниципаль районы |
| 2 (71) - 12 (21) | - Мөслим муниципаль районы |

"Азнакай муниципаль районы"
муниципаль берәмлеге составына керүче
шәһәр һәм авыл җирлекләре

| Карта-схемадагы № | Муниципаль берәмлек |
|---|---|
| 1 | Азнакай шәһәре |
| 2 | Актүбә шәһәр тибындагы поселогы |
| 3 | Әгерҗе авыл җирлеге |
| 4 | Әлкәй авыл җирлеге |
| 5 | Әсәй авыл җирлеге |
| 6 | Балтач авыл җирлеге |
| 7 | Бирючевка авыл җирлеге |
| 8 | Вахитов авыл җирлеге |
| 9 | Югары Стәрле авыл җирлеге |
| 10 | Илбәк авыл җирлеге |
| 11 | Кәкре Елга авыл җирлеге |
| 12 | Карамалы авыл җирлеге |
| 13 | Мәлбагыш авыл җирлеге |
| 14 | Мәсгут авыл җирлеге |
| 15 | Микулино авыл җирлеге |
| 16 | Сәпәй авыл җирлеге |
| 17 | Сарлы авыл җирлеге |
| 18 | Сукаеш авыл җирлеге |
| 19 | Татар Шуганы авыл җирлеге |
| 20 | Туйкә авыл җирлеге |
| 21 | Тымытык авыл җирлеге |
| 22 | Уразай авыл җирлеге |
| 23 | Урманай авыл җирлеге |
| 24 | Урсай авыл җирлеге |
| 25 | Үчәлле авыл җирлеге |
| 26 | Чалпы авыл җирлеге |
| 27 | Чемодурово авыл җирлеге |
| 28 | Чубар Абдул авыл җирлеге"; |

2) 4 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Азнакай муниципаль районы" муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында" Татарстан Республикасы Законына
4 нче кушымта

**Азнакай муниципаль районының "Актүбә шәһәр тибындагы поселогы" муниципаль берәмлеге территориясе чигенең картографик тасвирламасы**

Әлеге картографик тасвирлама "Актүбә шәһәр тибындагы поселогы" муниципаль берәмлеге территориясе чигенең карта-схемасын ("Азнакай муниципаль районы" муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында" Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта) тасвирлаудан гыйбарәт.

"Актүбә шәһәр тибындагы поселогы" муниципаль берәмлеге Мәлбагыш һәм Микулино авыл җирлекләре белән чиктәш.

**Азнакай муниципаль районының "Актүбә шәһәр тибындагы поселогы" муниципаль берәмлеге территориясе чиге**

"Актүбә шәһәр тибындагы поселогы" муниципаль берәмлеге чиге Мәлбагыш авыл җирлеге белән чиктәш җирдә "Актүбә шәһәр тибындагы поселогы" муниципаль берәмлеге, Мәлбагыш һәм Микулино авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Каменка авылыннан 2,0 км көнбатышта урнашкан 59 нчы тоташу ноктасыннан алып авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 30 м төньяк-көнчыгышка таба, 150 м көньякка таба, 75 м көньяк-көнбатышка таба уза, көньяк-көнчыгышка таба борыла, Әлмәт – Азнакай автомобиль юлын кисеп үтә һәм автомобиль юлы буйлап 800 м күмәк бакчага кадәр бара, аннары күмәк бакча чиге буйлап 250 м төньяк-көнчыгышка таба, 100 м көньяк-көнчыгышка таба уза, алга таба 1,1 км төньяк-көнчыгышка таба "Азнакай урманчылыгы" Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Мәлбагыш участок урманчылыгындагы 129 нчы урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап аның төньяк почмагына кадәр бара, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 250 м төньяк-көнчыгышка таба, 1,0 км көньяк-көнчыгышка таба, сынык сызык ясап, 300 м көньяк-көнбатышка таба "Азнакай урманчылыгы" Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Мәлбагыш участок урманчылыгындагы 129 нчы урман кварталының аерым торган кишәрлегенең төньяк почмагына кадәр бара, шуннан соң, сынык сызык ясап, 390 м көньякка таба бу урман кварталының төньяк һәм көнбатыш чикләре буйлап "Актүбә шәһәр тибындагы поселогы" муниципаль берәмлеге, Мәлбагыш һәм Микулино авыл

җирлекләре чикләре тоташкан урында Каменка авылыннан 1,0 км көньяк-көнбатышта урнашкан 58 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

"Актүбә шәһәр тибындагы поселогы" муниципаль берәмлеге чиге Микулино авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 58 нче тоташу ноктасыннан алып, сынык сызык ясап, 2,16 км көньякка таба "Бөгелмә урманчылыгы" Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Актүбә участок урманчылыгындагы 4, 12 нче урман кварталларының көнбатыш чиге буйлап автомобиль юлына кадәр уза, 970 м көньяк-көнчыгышка таба әлеге автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның төньяк чиге буйлап уза, автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтә һәм авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, сынык сызык ясап, 740 м көньякка таба, сынык сызык ясап, 130 м көньяк-көнбатышка таба, 400 м төньяк-көнбатышка таба, 40 м көнчыгышка таба, 60 м төньякка таба, 40 м көнбатышка таба, 40 м көньякка таба, 150 м төньяк-көнбатышка таба сәнәгать объектының көньяк-көнчыгыш почмагына кадәр бара, алга таба әлеге сәнәгать объектының көньяк-көнбатыш чиге буйлап 95 м төньяк-көнбатышка таба, төньяк-көнбатыш чиге буйлап 120 м төньяк-көнчыгышка таба һәм төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 45 м көньяк-көнчыгышка таба уза, аннары 350 м төньякка таба "Бөгелмә урманчылыгы" Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Актүбә участок урманчылыгындагы 12 нче урман кварталының көнчыгыш чиге буйлап автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосага кадәр бара, төньяк-көнбатышка таба әлеге автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның көньяк чиге буйлап бара, алга таба көньяк-көнбатышка таба 160 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 105 м карьерның көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 170 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бу урманчылыктагы 20 нче урман кварталының төньяк-көнчыгыш почмагына кадәр уза, уртак юнәлештә бу урман кварталының төньяк, көнбатыш һәм көньяк-көнбатыш чикләре буйлап көньякка таба бара, аннары 260 м төньяк-көнбатышка таба Актүбә – Алферовка автомобиль юлына бүлеп бирелгән полоса буйлап, аннары 150 м көньякка таба терлекчелек комплексына илтүче автомобиль юлына бүлеп бирелгән полоса буйлап уза, аннары төньяк-көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, Актүбә – Благодатный автомобиль юлына бүлеп бирелгән полоса буйлап озын чокырга кадәр бара, аны көнчыгыш, төньяк, көнбатыш һәм көньяк-көнбатыш чикләре буйлап әйләнеп үтә. Шуннан соң чик, сынык сызык ясап, 1,74 км көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, аннары уртак юнәлештә 1,7 км төньяк-көнчыгышка таба "Бөгелмә урманчылыгы" Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Актүбә участок урманчылыгындагы 19, 11 нче урман кварталларының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап бара, алга таба 11 нче урман кварталы буйлап 130 м төньяк-көнбатышка таба, 190 м төньякка таба, 110 м көнчыгышка таба бара, шуннан соң 240 м төньяк-көнчыгышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, аннары төньякка таба әлеге сәнәгать объектының көнбатыш чиге буйлап бара, алга таба бу урманчылыкның 11 нче урман кварталы чиге буйлап 70 м төньяк-көнчыгышка таба, 110 м төньякка таба, аннары бу урман кварталы буйлап 170 м төньяк-көнбатышка таба, сынык сызык ясап, 860 м көньяк-көнбатышка таба, 80 м көнбатышка таба бара, шуннан соң авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 60 м көньякка таба, 796 м төньяк-көнбатышка таба, 140 м төньяк-көнчыгышка таба, 50 м төньякка таба, 120 м төньяк-көнбатышка таба, 100 м төньякка таба, 140 м төньяк-көнчыгышка таба, 95 м төньяк-

көнбатышка таба, сынык сызык ясап, 405 м төньяк-көнчыгышка таба, 80 м көньяк-көнчыгышка таба автомобиль юлына кадәр уза, әлеге автомобиль юлы буйлап 550 м төньяк-көнчыгышка таба автомобиль юллары кисешкән җиргә кадәр бара, аннары шул ук юнәлештә, Әлмәт – Азнакай автомобиль юлын кисеп үтеп, 300 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, шуннан соң авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 80 м көньяк-көнчыгышка таба, 200 м төньяк-көнчыгышка таба, 350 м көньяк-көнчыгышка таба, 200 м төньяк-көнчыгышка таба, 400 м көньяк-көнчыгышка таба һәм 1,0 км төньяк-көнчыгышка таба 59 нчы тоташу ноктасына кадәр бара.";

3) 15 нче кушымтада:

а) җиденче абзацта "850 м көньяк-көнбатышта урнашкан 58 нче тоташу ноктасына" сүзләрен "1,0 км көньяк-көнбатышта урнашкан 58 нче тоташу ноктасына" сүзләренә алмаштырырга;

б) сигезенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Мәлбагыш авыл җирлеге чиге "Актүбә шәһәр тибындагы поселогы" муниципаль берәмлеге белән чиктәш җирдә 59 нчы тоташу ноктасыннан алып авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 30 м төньяк-көнчыгышка таба, 150 м көньякка таба, 75 м көньяк-көнбатышка таба уза, көньяк-көнчыгышка таба борыла, Әлмәт – Азнакай автомобиль юлын кисеп үтә һәм автомобиль юлы буйлап 800 м күмәк бакчага кадәр бара, аннары күмәк бакча чиге буйлап 250 м төньяк-көнчыгышка таба, 100 м көньяк-көнчыгышка таба уза, шуннан соң 1,1 км төньяк-көнчыгышка таба "Азнакай урманчылыгы" Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Мәлбагыш участок урманчылыгындагы 129 нчы урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап аның төньяк почмагына кадәр бара, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 250 м төньяк-көнчыгышка таба, 1,0 км көньяк-көнчыгышка таба, сынык сызык ясап, 300 м көньяк-көнбатышка таба "Азнакай урманчылыгы" Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Мәлбагыш участок урманчылыгындагы 129 нчы урман кварталының аерым торган кишәрлегенең төньяк почмагына кадәр бара, шуннан соң, сынык сызык ясап, 390 м көньякка таба бу урман кварталының төньяк һәм көнбатыш чикләре буйлап 58 нче тоташу ноктасына кадәр уза.";

4) 17 нче кушымтада:

а) дүртенче абзацта "850 м көньяк-көнбатышта урнашкан 58 нче тоташу ноктасына" сүзләрен "1,0 км көньяк-көнбатышта урнашкан 58 нче тоташу ноктасына" сүзләренә алмаштырырга;

б) бишенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Микулино авыл җирлеге чиге "Актүбә шәһәр тибындагы поселогы" муниципаль берәмлеге белән чиктәш җирдә 58 нче тоташу ноктасыннан алып, сынык сызык ясап, 2,16 км көньякка таба "Бөгелмә урманчылыгы" Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Актүбә участок урманчылыгындагы

4, 12 нче урман кварталларының көнбатыш чиге буйлап автомобиль юлына кадәр уза, 970 м көньяк-көнчыгышка таба әлеге автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның төньяк чиге буйлап уза, автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтә һәм авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, сынык сызык ясап, 740 м көньякка таба, сынык сызык ясап, 130 м көньяк-көнбатышка таба, 400 м төньяк-көнбатышка таба, 40 м көнчыгышка таба, 60 м төньякка таба, 40 м көнбатышка таба, 40 м көньякка таба, 150 м төньяк-көнбатышка таба сәнәгать объектының көньяк-көнчыгыш почмагына кадәр бара, шуннан соң 95 м төньяк-көнбатышка таба әлеге сәнәгать объектының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, 120 м төньяк-көнчыгышка таба төньяк-көнбатыш чиге буйлап һәм 45 м көньяк-көнчыгышка таба төньяк-көнчыгыш чиге буйлап уза, аннары 350 м төньякка таба "Бөгелмә урманчылыгы" Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Актүбә участок урманчылыгындагы 12 нче урман кварталының көнчыгыш чиге буйлап автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосага кадәр бара, төньяк-көнбатышка таба әлеге автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның көньяк чиге буйлап бара, шуннан соң көньяк-көнбатышка таба 160 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 105 м карьерның көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 170 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бу урманчылыктагы 20 нче урман кварталының төньяк-көнчыгыш почмагына кадәр уза, уртак юнәлештә көньякка таба бу урман кварталының төньяк, көнбатыш һәм көньяк-көнбатыш чикләре буйлап бара, аннары 260 м төньяк-көнбатышка таба Актүбә – Алферовка автомобиль юлына бүлеп бирелгән полоса буйлап, алга таба 150 м көньякка таба терлекчелек комплексына илтүче автомобиль юлына бүлеп бирелгән полоса буйлап уза, аннары төньяк-көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, Актүбә – Благодатный автомобиль юлына бүлеп бирелгән полоса буйлап озын чокырга кадәр бара, аны көнчыгыш, төньяк, көнбатыш һәм көньяк-көнбатыш чикләре буйлап әйләнеп үтә. Шуннан соң чик, сынык сызык ясап, 1,74 км көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, аннары уртак юнәлештә 1,7 км төньяк-көнчыгышка таба "Бөгелмә урманчылыгы" Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Актүбә участок урманчылыгындагы 19, 11 нче урман кварталларының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап бара, шуннан соң 11 нче урман кварталы буйлап 130 м төньяк-көнбатышка таба, 190 м төньякка таба, 110 м көнчыгышка таба бара, шуннан соң 240 м төньяк-көнчыгышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, аннары төньякка таба әлеге сәнәгать объектының көнбатыш чиге буйлап бара, алга таба бу урманчылыктагы 11 нче урман кварталы чиге буйлап 70 м төньяк-көнчыгышка таба, 110 м төньякка таба бара, аннары бу урман кварталы буйлап 170 м төньяк-көнбатышка таба, сынык сызык ясап, 860 м көньяк-көнбатышка таба, 80 м көнбатышка таба бара, шуннан соң авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 60 м көньякка таба, 796 м төньяк-көнбатышка таба, 140 м төньяк-көнчыгышка таба, 50 м төньякка таба, 120 м төньяк-көнбатышка таба, 100 м төньякка таба, 140 м төньяк-көнчыгышка таба, 95 м төньяк-көнбатышка таба, сынык сызык ясап, 405 м төньяк-көнчыгышка таба, 80 м көньяк-көнчыгышка таба автомобиль юлына кадәр уза, 550 м төньяк-көнчыгышка таба әлеге автомобиль юлы буйлап автомобиль юллары кисешкән җиргә кадәр бара, аннары, Әлмәт – Азнакай автомобиль юлын кисеп үтеп, шул ук юнәлештә 300 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, шуннан соң авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 80 м көньяк-көнчыгышка таба, 200 м төньяк-көнчыгышка таба,

350 м көньяк-көнчыгышка таба, 200 м төньяк-көнчыгышка таба, 400 м көньяк-көнчыгышка таба һәм 1,0 км төньяк-көнчыгышка таба 59 нчы тоташу ноктасына кадәр бара.";

в) унберенче абзацны үз көчен югалткан дип танырга.

**3 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.


Татарстан Республикасы
Президенты

Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2010 елның 22 мае
№ 28-ТРЗ

«Аерым муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен үзгәртү һәм «Азнакай муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Законына кушымта

## Азнакай муниципаль районының аерым муниципаль берәмлекләре чикләре үзгәрешенең карта-схемасы




Шартлы билгеләр

- район чиге
- җирлекләрнең чикләре
- торак пункт
- I – Мәлбагыш авыл җирлеге территориясе составына кертелүче «Актүбә шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге территориясе
- II - «Актүбә шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге территориясе составына кертелүче Микулино авыл җирлеге территориясе
- III – Микулино авыл җирлеге территориясе составына кертелүче «Актүбә шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге территориясе
- IV - «Актүбә шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге территориясе составына кертелүче Мәлбагыш авыл җирлеге территориясе